2024 елнын 27 мартында “Педагог 13.” мәйданчыгында туган телне (мокша, әрзә, татар) һәм туган әдәбиятны укытуда, система булдыручы vзәк буларак, традицион Россия кыйммәтләре” тобәкара семинары узды. Әлеге семинарда Мордовия Республикасы һәм мордва халкы тупланып яшәгән тобәкләрнен мәгариф оешмаларыннан 40 туган тел һәм әдәбият педагогы катнашты.

Россия Федерациясендә Гаилә елына багышланган семинарнын максаты - туган телне һәм әдәбиятны укытунын заманча практикалары турындагы тәжрибәне диссеминацияләv.

Үзәкнен этномәдәни белем бирv лабораториясе модире *Наумова Елена Михайловна* “Традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау – бу vсеп килvче буынны тәрбияләvнен топ бурычларынын берсе”, – дип билгеләп vтте семинар модераторы. Тобәкара семинарда катнашучыларга сәламләv сvзе белән “Педагог 13” ректоры *Татьяна Васильевна Самсонова* vзенен чыгышында гаилә һәр кешенен тормышында ин моһиме булуын билгеләп vтте. Монда мәхәббәт, хормәт, кайгырту, зирәклек һәм жаваплылык ойрәтелә.

Тобәкара семинар эшендә «Россия Федерациясе халыкларынын туган телләре федераль институты»нын этномәдәни белем бирv һәм конкурс эшчәнлеге бvлегенен әйдәп баручы белгече *Марина Мансур кызы Салихова* (Мәскәv шәһәре) катнашты. Марина Мансур кызы хезмәттәшләренен игътибарын туган телләр институтынын традицион кыйммәтләрне, тел кvпторлелеген һәм мәдәни мирасны саклау коралы буларак проектларына юнәлтте.

Шулай ук семинар эшендә Мордовия Республикасы мәгариф оешмаларынын тvбәндәге педагоглары катнашты:

- *Ольга Викторовна Кочеваткина*, филология фәннәре кандидаты, Саранск шәһәре 28 нче урта гомуми белем бирv мәктәбе укыту-тәрбия эше буенча директор урынбасары, эрзә теле укытучысы: “Мордва халкынын мифология-сен ойрәнv мисалында укучыларны Россиянен традицион кыйммәтләренә жәлеп итv”;
- *Марина Николаевна Миронова*, рус теле һәм әдәбияты, мордва (мокша) теле укытучысы Советлар Союзы Герое М.П.Девятаев исемендәге Саранск

шәһәре 15 мәктәбе: “Гаилә традицияләре дәресләрдә һәм дәрестән тыш эштә әдәбият укыту-чысынын тәрбия эшчәнлегенен бер аспекты буларак”;
- *Равиль Харис улы Казанбаев*, Мордовия Республикасы Кадошкино урта гомуми белем бирv мәктәбенен тарих укытучысы: “XIX гасыр ахырында XX гасыр башында Пенза губернасынын Инсар оязе татар-мишәрләренен мәгариф системасы”;
- “Ел укытучысы – 2024” нен 10 апреленә кадәр vтә торган Мордовия муниципаль туры катнашучылары - *Юлия Рэшит кызы Рамазанова* белән *Земфира Хафиз кызы Мангутова* , Саранск шәһәренен 11нче урта мәктәбе башлангыч сыйныфларда татар теле укытучылары: “Кече мәктәп укучыларын дәрестән тыш дәресләрдә әхлакый тәрбияләv һәм укыту”;
- *Алмаз Кериш кызы Янгляева*, Ләмберә районынын 1нче номерлы урта мәктәбе татар теле укытучысы: “Туган татар телен һәм милли традицияләрен саклауда һәм vстерvдә гаиләнен роле”;
- *Зульфия Захир кызы Сюбаева*, Ләмберә районынын 1нче номерлы урта мәктәбендә педагог-оештыручы: “Безнен гаиләдә туган тел”;
- *Рауза Мукаддяс кызы Юмаева*, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы: “Гаилә буыннарнын озлексез бәйләнеше”.

Тобәкара семинарда катнашучылар мондый нәтижәгә килделәр: Ватаныбызнын киләчәге Россия яшьләренен игелек, намуслылык, гаделлек, хезмәт соючәнлек һәм Ватанга хезмәт итәргә әзерлек принципларында тәрбияләнvенә бәйле.

Наилә НАСЫРОВА әзерләде